**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2022 елның «12» сентябреннән № 255

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә балалар сәнгать мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе тарафыннан эшчәнлеккә керем китерә торган түләүле хезмәтләр күрсәтү турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2022 елның 17 августындагы 221 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә Балалар сәнгать мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе тарафыннан эшчәнлеккә керем китерә торган түләүле хезмәтләр күрсәтү турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә балалар сәнгать мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе тарафыннан эшчәнлеккә керем китерә торган түләүле хезмәтләр күрсәтү турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2022 елның 17 августындагы 221 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә Балалар сәнгать мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе тарафыннан эшчәнлеккә керем китерә торган түләүле хезмәтләр күрсәтү турындагы нигезләмәнең 1.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Әлеге Нигезләмә 1994 елның 30 октябрендәге 51-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Гражданнар кодексы, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль Закон, «Кулланучылар

хокукларын яклау турында» 1992 елның 07 февралендәге 2300-1 номерлы Россия Федерациясе Законы, «Түләүле белем бирү хезмәтләре күрсәтү кагыйдәләрен раслау турында»» 2020 елның 15 сентябрендәге 1441 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Татарстан Республикасы дәүләт (муниципаль) мәгариф оешмалары тарафыннан бирелә торган физик (юридик) затларга түләүле хезмәтләр күрсәтү тәртибе турында регламентны раслау хакында» 2014 елның 06 маендагы 2556/14 номерлы боерыгы, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә балалар сәнгать мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе (алга таба – мәктәп) уставы нигезендә эшләнгән.

Әлеге нигезләмә регламентлый:

Мәктәпнең түләүле өстәмә белем бирү хезмәтләрен оештыру өлешендә эшчәнлеген;

Мәктәп һәм Заказчы арасында өстәмә түләүле белем бирү хезмәтләре күрсәткәндә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне.».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» нда http//pravo.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http//novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фасахов